Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин З.М. Вәлиәхмәтов шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2016 елның 27 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин З.М. Вәлиәхмәтовның шикаять формасындагы мөрәҗәгате сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган

норматив хокукый актның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын, яклар — гражданин З.М. Вәлиәхмәтов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге башлыгы Р.Г. Миңнеголов, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге башлыгы А.А. Вәлиева аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Л.К. Вәлиуллина, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Ш.Ш. Гафиятуллин, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинова чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм

башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин З.М. Вәлиәхмәтов Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) аерым нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган Тәртип Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга, качакларга, шул исәптән инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүне регламентлаштыра.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — I төркем инвалиды һәм аның тернәкләндерүнең индивидуаль программасы нигезендә ул елга 1—2 тапкыр тернәкләндерү үзәгендә социомәдәни тернәкләндерү үтәргә мохтаҗ. Ләкин ул билгеләп үткәнчә, дәгъвалана торган Тәртип белән аталган хезмәтне социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә күрсәтүнең башка ешлыгы билгеләнгән — ике елга 1 тапкыр. Шуның нигезендә аның тернәкләндерүнең индивидуаль программасында каралган ешлык белән социаль хезмәтләр аңа күрсәтелми. Моннан тыш, аның фикеренчә, аның һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче арасында төзелә торган шартнамә нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу законсыз, чөнки аларны күрсәтү бушлай булырга, аның тернәкләндерүнең индивидуаль

программасы нигезендә һәм бары тик «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәгендә башкарылырга тиеш.

Гражданин З.М. Вәлиәхмәтов дәгъвалана торган хокукый җайга салу аның конституциячел хокукларын боза дип саный һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28, 52, 54 һәм 58 статьяларына каршы килә дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; Татарстан Республикасында һәркем, сәламәтлек саклауның дәүләт һәм бүтән учреждениеләре законда билгеләнгән тәртиптә күрсәтә торган медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлеген саклауга хокуклы; дәүләт гражданнарның сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итә торган эшчәнлекне хуплый; һәркемгә яше буенча, авырган, гариплңгән һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; дәүләт пенсияләре һәм социаль пособиеләр закон белән билгеләнә; социаль тәэминатның өстәмә рәвешләрен булдыру хуплана; Татарстан Республикасы Конституциясендә төп хокукларны һәм ирекләрне санап чыгу кешенең һәм гражданның гомумтанылган башка хокукларын һәм ирекләрен кире кагу һәм кимету буларак аңлатылмаска тиеш; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

1.1. Мөрәҗәгать итүче үзенең шикаятендә шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы дәгъвалана торган карары (алга таба шулай ук — карар) һәм аның белән расланган Тәртип гомуми танышу өчен рәсми рәвештә тулы күләмдә

«Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгарылмаганнар дип күрсәтә, бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясына (өченче өлеш) һәм 48 статьясына (икенче өлеш) каршы килә, алар нигезендә кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый акт, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, әгәр законда башкасы каралмаган булса, һәркемгә аның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы үзләренең карарлары һәм башка материаллар белән танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Тапшырылган материалларны өйрәнеп, эштә катнашучы яклар һәм затларның чыгышларын тыңлагач, Татарстан Республикасы Конституция суды гражданин З.М. Вәлиәхмәтовның әлеге өлештәге дәлилләре белән түбәндәге нигезләр буенча килешә алмый.

«Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (дәгъвалана торган норматив хокукый актны кабул итү моментына гамәлдә булган 2014 елның 25 декабрендәге редакциясендә) 5 статьясы нигезендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару көне булып «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре, республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналында «рәсми рәвештә бастырып чыгарыла» тамгасы белән тулы текстның беренче мәҗбүри публикациясе яисә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) яки «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) санала.

«Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары тулы күләмдә 2015 елның 16 мартында «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарылган, әлеге портал, мөрәҗәгать итүче дәлилләренә каршы, «Республика Татарстан» һәм «Ватаным Татарстан» газеталары белән беррәттән бертигез рәсми рәвештә бастырып чыгару чыганагы булып тора.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Законының югарыда китерелгән нормалары мәгънәсе буенча дәгъвалана торган карарның рәсми рәвештә басылып чыгу көне булып 2015 елның 16 марты санала.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законы белән кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары рәсми басылып чыккан көннәреннән соң 10 көн узгач үз көченә керәләр, әгәр актларның үзләрендә аларның бүтән, соңрак, үз көченә керү вакыты билгеләнгән булмаса (6 статья), дип билгеләнгәнгә игътибар итәргә тиешле дип саный. Әлеге тәртипне үтәү мәҗбүри, чөнки ул закон таләпләренә нигезләнгән мөһим процессуаль элемент булып тора. Моңа Россия Федерациясе Конституция Суды да күрсәтә, аның хокукый позициясе буенча федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларының легальлеге аларда билгеле, законга каршы килмәгән норматив эчтәлекнең (гомуми кагыйдәнең) булуын гына таләп итмичә, тиешле законлы форманы, кабул итү һәм игълан итү тәртибен үтәүне дә күздә тота; гамәлдәге хокукый җайга салу системасында андый норматив актны суд тарафыннан тикшерү үз эченә аның норматив күрсәтмәләренең эчтәлеге, акт формасы, шулай ук аны чыгарган субъект, кабул итү, бастыру һәм гамәлгә кертү

тәртибе буенча федераль законга ярашлы булу-булмавын билгеләүне кертә (2015 елның 31 мартындагы 6-П номерлы Карар). Күрсәтелгән хокукый позиция Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларына карата да тулысынча кулланылырга мөмкин.

Димәк, дәгъвалана торган карар 2015 елның 26 мартыннан иртәрәк үз көченә кермәскә тиеш иде. Шулай да әлеге карарның 5 пункты белән аның 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керүе каралган. Шулай итеп, дәгъвалана торган карарның үз көченә керү вакытын аның рәсми рәвештә басылып чыгу көненнән иртәрәк билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча норматив хокукый актның законда билгеләнгән үз көченә керү тәртибен бозган.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясы белән үзара бәйләнештә 103 статьясы нигезендә дәгъвалана торган нормаларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүгә тикшерү чикләре шул исәптән аларны гамәлгә кертү тәртибе буенча билгеләнә.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карала торган карарын аның үз көченә керү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануның 2015 елның 1 гыйнварыннан 26 мартына кадәрге чорда гражданнарга күрсәтелгән социаль хезмәтләрнең законлылыгын шик астына куярга мөмкинлек бирә алу фактын да игътибарга ала. Мондый нәтиҗә конституциячел суд эшләрен башкару максатларына каршы килер иде, алар Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы буенча Татарстан Республикасының конституциячел корылышын, кешенең төп хокукларын һәм ирекләрен яклаудан, Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының хокукый системасында өстенлеген һәм аның бөтен территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуын тәэмин итүдән гыйбарәт.

Бәян ителгәннәр нигезендә, шулай ук гражданин З.М. Вәлиәхмәтовның шикаяте бирелү моментына «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр

күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карарының законда билгеләнгән тәртиптә үз көченә кергән булуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә аның үз көченә керү тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәвен танудан тыелып кала. Шулай да кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча норматив хокукый актларның, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан чыгарыла торганнарның үз көченә керү тәртибенә куелган закон таләбен үтәү Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең барлык органнары өчен мәҗбүри, ә әлеге таләпне бозу — рөхсәт ителми.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Мөрәҗәгать итүче килешмәгән социаль хезмәтләр күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү ешлыгы инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә ике елга 1 тапкыр тәшкил итә дигән норма Тәртипнең V бүлегенең 5.4 бүлекчәсендәге 5.4.2 пунктының (алга таба — 5.4.2 пункт) икенче абзацында бар. Социаль хезмәтләрне бушлай яки түләүле яисә өлешчә түләүле нигездә күрсәтү кагыйдәләре Тәртипнең V бүлегенең 5.2 бүлекчәсендәге 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктлары (алга таба — 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктлар) белән билгеләнгән, ә социаль

хезмәтләрне шартнамә нигезендә күрсәтү — Тәртипнең V бүлегенең 5.3 бүлекчәсендәге 5.3.1 пункты (алга таба — 5.3.1 пункт) белән.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең 5.4.2 пунктындагы икенче абзацының, үзара бәйле 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктларының, шулай ук 5.3.1 пунктының хокукый нигезләмәләре әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау өлкәсенә карый, ул Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» пункты) нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында, шуңа күрә Татарстан Республикасы әлеге өлкәдә хокукый җайга салуны федераль законнар нигезендә һәм аның законнары, башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килмәсә генә, гамәлгә ашырырга хокуклы (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясындагы 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт хакимиятенең федераль органнары вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен билгели (1 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты). Шул ук вакытта аталган Федераль законның 8 статьясы нигезендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау керә (10 пункт).

Күрсәтелгән Федераль законны үтәү йөзеннән «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу

турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, аның нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтләренә керә (4 статьяның 8 пункты).

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган карарны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә карый торган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, аларның үтәлешен тикшерә.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 13 статьясы белән үзара бәйләнештә 54 статьясының беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм иркен үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт, һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасында һәркем, сәламәтлек саклауның дәүләт һәм бүтән учреждениеләре законда билгеләнгән тәртиптә күрсәтә торган медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлеген саклауга хокуклы (52 статья, беренче өлеш) дип игълан итә. Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 39 (1 өлеш) һәм 41 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Әлеге конституциячел нормалар 1996 елның 3 маендагы Европа социаль хартиясенең (яңадан каралган) 15 статьясындагы якларның, аерым алганда,

инвалидларга тулы социаль интеграциягә һәм җәмгыять тормышында катнашуга хокукны нәтиҗәле гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итү бурычын күздә тота торган нигезләмәләренә, шулай ук Инвалидлар хокуклары турындагы конвенциянең (БМО Генераль Ассамблеясы тарафыннан 2006 елның 13 декабрендә кабул ителгән, 2012 елның 3 маендагы 46-ФЗ номерлы Федераль закон белән ратификацияләнгән) инвалидларның лаеклы тормыш дәрәҗәсенә һәм социаль яклауга хокукын шулай ук таный торган 28 статьясына туры килеп торалар.

Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау өлкәсендә максаты инвалидларга Россия Федерациясе Конституциясе белән каралган граждан, икътисади, сәяси һәм башка хокукларны һәм ирекләрне гамәлгә ашыруда башка гражданнар белән тигез мөмкинлекләрне шулай ук халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә тәэмин итү булган дәүләт сәясәтен «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон билгели.

Күрсәтелгән Федераль законның 9 статьясындагы беренче өлеше нигезендә инвалидларны тернәкләндерү — инвалидларның көнкүреш, иҗтимагый, һөнәри һәм башка эшчәнлеккә сәләтләрен тулысынча яисә өлешчә торгызу системасы һәм процессы ул. Әлеге статьяның икенче өлешендәге дүртенче абзацына күрә социомәдәни тернәкләндерү инвалидларны тернәкләндерүнең төп юнәлешләренә карый. Үзенең асылы буенча социомәдәни тернәкләндерү инвалидларга массакүләм мәдәни-ял итү чараларында һәм социомәдәни эшчәнлектә тулысынча катнашу өчен шартлар тудыруны күздә тота.

Карала торган Федераль законның 10 статьясындагы икенче өлешен үтәү йөзеннән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 30 декабрендәге 2347-р номерлы күрсәтмәсе белән инвалидка күрсәтелә торган тернәкләндерү чаралары, тернәкләндерүнең техник чаралары һәм хезмәтләрнең федераль исемлеге расланган, анда тернәкләндерү чараларына торгызу терапиясе, реконструктив хирургия, шифаханә-курорт дәвалавы, протезлау һәм ортезлау, колак

аппаратларын бирү, инвалидларның һөнәри ориентацияләнүен тәэмин итү кирә. Тернәкләндерү чараларының әлеге федераль исемлегенә инвалидларны социомәдәни тернәкләндерү керми, чөнки ул инвалидларга аларның коммуникатив потенциалын күтәрү максатында күрсәтелә торган хезмәт булып тора һәм үзенең хокукый табигате буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 24 ноябрендәге 1236 номерлы карары белән расланган Социаль хезмәтләр төрләре буенча социаль хезмәтләрнең якынча исемлегенең 7 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә күрсәтелә торган социаль хезмәтләргә карый. Тиңдәш нигезләмә «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында бар (8 статьяның
7 өлешендәге 2 пункты).

Социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә карата таләпләр «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон белән регламентлаштырылган, аның нигезендә әлеге тәртип социаль хезмәт күрсәтү формалары (өйдә, ярымстационар яки стационар формаларында), социаль хезмәтләр төрләре буенча билгеләнә һәм үз эченә социаль хезмәт күрсәтү стандартын ала (27 статьяның 2 өлешендәге 2 пункты). Үз чиратында социаль хезмәт күрсәтү стандарты шул исәптән аны күрсәтү срокларын (ешлыгын) үз эченә ала (3 статьяның 5 пункты, 27 статьяның 3 өлешендәге 2 пункты).

Социаль хезмәт күрсәтүнең формасы һәм төреннән чыгып социаль хезмәтләр күрсәтүнең конкрет ешлыгы федераль законнарда билгеләнмәгән. Шуңа күрә социаль хезмәтләр күрсәтелүгә ихтыяҗны һәм гомумән Татарстан Республикасында инвалидларны тернәкләндерү үзәкләре белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә дәгъвалана торган Тәртиптә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүнең түбәндәге ешлыгын билгеләгән: халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплексны

үзәкләрнең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә — елга 2 тапкыр, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә — ике елга 1 тапкыр, ә инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә буш урыннар булганда (чират булмаганда) — елга 1 тапкыр (5.4.2 пунктның икенче абзацы).

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норманы Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүне җайга сала торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләре белән системалы берлектә карарга кирәк, чөнки гамәлдәге законнар белән социаль-тернәкләндерү чараларын социаль хезмәт күрсәтүнең шулай ук башка формаларында күрсәтү мөмкинлеге каралган. Шулай, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең III бүлегенең 3.4 бүлекчәсендәге 3.4.2 пунктының 2 абзацы нигезендә социаль хезмәтләр гражданнарга шулай ук социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә елга 2 тапкыр ешлык белән күрсәтелергә мөмкин.

Шулай итеп, дәгъвалана торган нигезләмәләр, мөрәҗәгать итүченең дәлилләренә каршы, гражданнарның социаль хезмәтләрне үзләренең сайлавы буенча һәм социаль хезмәт күрсәтүнең формасына (стационар яки ярымстационар) карап, төрле ешлык белән, шул исәптән аларның тернәкләндерүнең индивидуаль программасында каралган күләмдә алырга хокукларын чикләми.

Мондый хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясенең 13 статьясы нигезендә халыкны социаль яклау гарантияләрен тәэмин итәргә бурычлы социаль хокукый дәүләт максатлары белән яраша. Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе гражданнарның теге яки бу категорияләренә күрсәтелә торган социаль яклауның конкрет ысулларын һәм күләмен билгеләми — әлеге

мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының өстенлеге булып тора, ул, хокукый җайга салуны башкарганда социаль өлкәдә конституциячел гарантияләрне гамәлгә ашырып, социаль яклау чараларын билгеләгәндә, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлаганда һәм күрсәтелү шартларын регламентлаштырганда җитәрлек дәрәҗәдә ирекле эш итә (2016 елның 13 апрелендәге 11-П номерлы Карар, 2015 елның 9 июнендәге 1230-О номерлы Билгеләмә).

Димәк, Тәртипнең 5.4.2 пунктындагы икенче абзацының инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү ешлыгын ике елга 1 тапкыр итеп билгели торган нигезләмәләре гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзләренең эчтәлеге һәм максатчан билгеләнеше буенча дәүләт тарафыннан гражданнарның социаль яклауга хокукларын тормышка ашыру чараларын тәэмин итүгә юнәлгән механизмның бер элементы булып тора, үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән гражданин З.М. Вәлиәхмәтовның конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яки башкача боза торган итеп карала алмыйлар.

4. Социаль хезмәтләр, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешеннән аңлашылганча, гражданга социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче, граждан яки аның законлы вәкиле арасында төзелә торган шартнамә нигезендә күрсәтелә. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәнең әһәмиятле шарты булып шул исәптән социаль хезмәтләр күрсәтү кыйммәте тора, әгәр алар түләүле яки өлешчә түләүле нигездә күрсәтелсә (17 статьяның 2 өлеше). Эчтәлеге буенча тиңдәш нормалар Тәртипнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 5.3.1 пунктында бар.

Югарыда аталган Федераль закон белән социаль хезмәтләр бушлай күрсәтелә торган гражданнар категорияләре билгеләнгән (31 статьяның 1 өлеше). Шул ук вакытта күрсәтелгән статьяның 3 өлешендә Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары белән социаль хезмәтләр бушлай

күрсәтелә торган гражданнарның башка категорияләре каралырга мөмкин дип билгеләнгән.

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгәнчә, әгәр мөрәҗәгать итү датасына социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә бер кешегә уртача исәпләнгән кереме социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашырган өчен бер кешегә уртача исәпләнгән керемнең чик күләменнән аз яисә чик күләменә тигез булса, өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар һәм стационар формаларында социаль хезмәт күрсәтүләр түләүсез гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән социаль хезмәтләр бушлай күрсәтелә торган гражданнарның башка категорияләре каралырга мөмкин дип күрсәтелгән (11 статьяның 2 һәм 3 өлешләре).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Тәртипнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 5.2.2 пунктында билгеләгәнчә, социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр түләүле яки өлешчә түләүле нигездә күрсәтелә, моңа Тәртипнең 5.2.3 пунктында аталган социаль хезмәтләр бушлай күрсәтелә торган әлеге гражданнар категорияләре керми: гадәттән тыш хәлләр, коралллы милләтара (этносара) низаглар аркасында зыян күргән затлар; Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм анда катнашучылар; хәрби хәрәкәтләр инвалидлары һәм ветераннары; социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган гражданнар аларның гаиләсендә даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ инвалид (инвалид бала) булуга бәйле рәвештә; шулай ук җан башына уртача керемнәре социаль хезмәтләрне бушлай күрсәтү өчен җан башына уртача

керемнең Татарстан Республикасында билгеләнгән иң чик күләменнән түбәнрәк яки аңа тигез булган социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдаланучылар.

Гражданнарга тернәкләндерү хезмәтләрен аларның матди тәэмин ителеше дәрәҗәсенә карап бушлай күрсәтү мәсьәләсе әлеге мөрәҗәгать итүченең шикаяте буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. 2014 елның 29 октябрендәге 60-П номерлы карарындагы хокукый позиция нигезендә республикада билгеләнгән пенсия һәм яшәү минимумы күләме нисбәтеннән чыгып, дәүләт тернәкләндерү хезмәтләрен күрсәтү шартларының дифференциациясе өлкән яшьтәге гражданның һәм инвалидның матди тәэмин ителеше дәрәҗәсе (күләме) кебек объектив хәлне исәпкә алуга нигезләнә. Бу хәл түләүсез тернәкләндерү хезмәтләре рәвешендәге әһәмиятлерәк социаль ярдәмне әлеге гражданнарның матди ярдәмгә аеруча мохтаҗ категорияләренә күрсәтүне шарт итеп куя. Моннан чыгып, әлеге дифференциация гражданнарны, шул исәптән мөрәҗәгать итүчене дә кимсетә торган һәм аларның конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмый, чөнки ул гражданнарның социаль яктан аеруча якланмаган категорияләренә ярдәм итүгә юнәлдерелгән, шулай ук федераль законнарның тиешле нормаларына нигезләнә.

Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында берничә мәртәбә гражданнарның аерым категорияләре тарафыннан теге яисә бу хокукны гамәлгә ашыру шартларында аерымлыклар, әгәр алар объектив акланган, нигезле булса һәм конституциячел әһәмиятле максатларны күздә тотса, ә бу максатларга ирешү өчен кулланыла торган хокукый чаралар аларга туры килсә, булырга мөмкин дип күрсәтте (2013 елның 30 гыйнварындагы 3-П номерлы, 2013 елның 22 ноябрендәге 25-П номерлы карарлар, 2016 елның 14 гыйнварындагы 135-О номерлы Билгеләмә).

Мондый алым шулай ук 1966 елның 16 декабрендәге Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактны гамәлгә ашыруны тикшереп торучы Кеше хокуклары буенча комитетның хокук куллану практикасына туры килә, аның нигезендә закон каршында тигез булу хокукы һәм бернинди дискриминациясез законны тигез яклау хокукы теләсә кайсы аерымлык дискриминацияле дигәнне

аңлатмый, шуңа күрә резонлы һәм объектив критерийларга нигезләнгән дифференциация Пактның 26 статьясы мәгънәсе буенча тыелган дискриминация белән бер үк түгел (Комитетның 1987 елның 9 апрелендәге 182/1984 номерлы карарының 13 пункты).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең V бүлегендәге 5.4 бүлекчәсенең 5.4.2 пунктындагы икенче абзацының, V бүлегендәге 5.2 бүлекчәсенең үзара бәйле 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктларының, шулай ук V бүлегендәге 5.3 бүлекчәсенең 5.3.1 пунктындагы дәгъвалана торган хокукый нигезләмәләре үзләренең эчтәлеге һәм конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар, шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 13, 28, 52, 54 һәм 58 статьяларына каршы килмиләр.

Гражданин З.М. Вәлиәхмәтовка социаль хезмәтләрне «Идел» инвалидларны социаль тернәкләндерү республика үзәгендә бушлай күрсәтүдән баш тартуга сәбәпче булган хәлләрнең законлы һәм нигезле булу-булмавын тикшерү эшнең фактагы хәлләрен ачыклауны күздә тота, бу исә Татарстан Республикасы Конституция судының компетенциясенә керми, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда фактагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы

өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенең V бүлегендәге 5.4 бүлекчәсенең 5.4.2 пунктындагы икенче абзацының, V бүлегендәге 5.2 бүлекчәсенең үзара бәйле 5.2.2 һәм 5.2.3 пунктларының, шулай ук V бүлегендәге 5.3 бүлекчәсенең 5.3.1 пунктындагы хокукый нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 71-П** **Татарстан Республикасы Конституция суды**